ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ
Ил-көн вакыйгаларына хәбәрчебез карашы
> 2

БЕЛЕМ ЭСТӘҮ
Фәнгә игътибар һәм аның белән кызыксынучылар артканмы?
> 2

«АЛДЫНГЫЛАР» ФИКЕРЕ
Яшьләргә ни кирәген яшьләр яхшырак белә
> 2



ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр биредә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 17 (29177) | Чәршәмбе | 7 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КУЛ АСТЫНДА БУЛСЫН

АВЫЛДАГЫ ФАПЛАРДА ДАРУ САТЫЛА БАШЛАЯЧАК

Авыл җирендә эшләүче фельдшерлар халыкны дәвалап кына калмыйча, аларга кирәкле даруларны да сатачак. Моңа кадәр бу эш белән фармацевтлар гына шөгыльләнә ала иде. Россия Дәүләт Думасы беренче утырышта әнә шундый закон проектын хуплаган. Бу яңалык үзендә даруханәсе булмаган авылларга кагыла.

Проект авторлары фикеренчә, бүген ил төбәкләренең яртысыннан артыгында авыл халкын дарулар белән тәэмин итү бик түбән дәрәҗәдә. Рәсми саннардан аңлашылганча, шундый һәр төбәктә даруханәсе булмаган 100дән артык авыл исәпләнә. Анда яшәүчеләр кирәкле даруны 50–60 чакрым ераклыктагы даруханәдән барып алырга мәҗбүр.

Законга кертелгән яңа төзәтмәләр дару сатарга рөхсәт биргән лицензияне кулга төшерү шартларын да җиңеләйтә. Хәзер аны алу өчен авылдагы ФАП, табиблык амбулаториясендә провизор, фармацевт булу мәҗбүри түгел. Биредә эшләүче медицина хезмәткәренең махсус белеме булу да җитә. Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин моны бик мөһим яңалык дип атаган.

– Безгә авыл җирендә яшәүчеләрдән бик күп мөрәҗәгатьләр килә. Аларның күбесе дарулар белән тәэмин ителеш начар булудан зарлана. Хәзерге вакытта авылда яшәүчеләрнең күбесе дару алырга район үзәге яки шәһәргә үк барырга мәҗбүр. Өлкән кеше өчен бу бигрәк тә авыр бит, – дигән Володин законга кертелгән төзәтмәләр уңаеннан.

Мамадыш районының Катмыш авылында яшәүчеләр ул яктан бәхетле. Дару кирәк булса, үзләренең

Роман ӘХМӘТҖАНОВ,
Спас үзәк район хастаханәсе баш табибы:
– Бу закон проектына уңай карыйм. Кайбер авылларда яшәүчеләргә дару алу өчен 90 чакрым юл узарга кирәк бит. Башта район үзәк хастаханәсенә барып, табибтан ташламалы даруга рецепт алырга, шуның белән даруханәдән препаратларны алып, кире авылга кайтырга кирәк. Бу бик уңайсыз. Яңа закон проекты исә, бер яктан, безнең эшне җиңеләйтә, икенче яктан, авылда яшәүчеләрнең дә тормышын яхшырта. Без бу яктан бер адым алдан барабыз. Авылда яшәүче һәм өеннән чыгып йөри алмаган өлкәннәребез фельдшер исеменә ышаныч кәгазе яза. Ул, үз чиратында, кемгә нинди дару кирәклеген барлап чыккач, районга барып дарулар алып кайта да өлкәннәргә өләшә. Шул рәвешле алар өйдән чыкмыйча гына дарулар белән тәэмин ителә.

ok.ru

ФАПларына баралар да алып кайталар. «Фельдшерда, ялга китәсе булса, авылның «Ватсап»тагы төркеменә: «Дарулар килеп алыгыз», – дип яза. Кыйммәтле, сирәк кулланыла торган даруларны район үзәгенә барып яки бездән 12 чакрым ераклыктагы участок амбулаториясендә урнашкан даруханәдән алабыз», – ди алар.

Авыл халкы бу яңалыкны шатланып кабул итсә дә, фельдшерлар, эшебез тагын да артмасмы, дип борчыла. Бу аңлашыла да. Бүген аларның болай да тавык чүпләп бетермәслек кырыкмаса кырык төрле эше бар. Берүзе берничә авылга хезмәт күрсәткән фельдшерлар да шактый бит. Питрәч районының Тау Иле авылы фельдшеры Алинә Мөхәмәтдинова, мәсәлән, барлыгы 644 кешегә хезмәт күрсәтә. Татар Тау Иленнән тыш, күршедәге Рус Тау Иле, Княжа авылларында яшәүчеләр дә – Алинә карамагында. Без элемтәгә кергәндә дә, чистартылмаган карлы авыл урамын ерып, авырулар янына ашыгуы иде.

– Бу яңалык безгә былтыр килеп җиткән иде инде. Кайбер ФАПларда дару сата башладылар. Лицензия булмагач, бездә сатарга рөхсәт итмәделәр. Кирәкле даруларны районга баргач үзем алып кайтам. Ул үзебезнең ФАПта гына сатылса, уңайлырак булыр иде, билгеле. Икенче яктан, безгә эш тә артачак, – ди ул.

Саба районының Олы Шыңар фельдшер-акушерлык пунктында 36 ел фельдшер булып эшләүче Рузилә Мөхәммәтова да шул фикердә. Авылда дару сату белән фельдшер түгел, махсус кеше шөгыльләнергә тиеш дип саный ул.

– Дару сату – мәшәкатьле эш. Аңа гел заказ биреп, кайтканын урнаштырып, хисабын алып барырга кирәк. Бер кешегә халыкка медицина ярдәме дә күрсәтү, аннан тыш шушы дару сату эшен дә алып бару бик авыр, – ди Рузилә ханым. – Даруханә булмаган авылларда даруны медпунктларда сатуга уңай карыйм. Ялгыз яшәгән, дару алып кайтып бирерлек кешесе булмаган әби-бабайларга бигрәк тә уңайлы бу. Элегрәк бездә бөтен дару да бар иде. Киштә беркайчан да буш тормады. Дарулар бетә башлауга, яңадан алып кайтып куя идек. Хәзер даруны гариза буенча – кемгә күпме кирәк, шулкадәр күләмдә генә алып кайтабыз. Бу уңайсызрак, билгеле. Кешегә бит аңа гел бертөрле генә дару кирәкми. Бүген баш авыртканнан дару кирәк булса, иртәгә кул астында йөрәк авыртканнан дару булмаска мөмкин. Гариза буенча гына кайтарткач, кирәк чакта гына медпунктта ул дарулар булмый, билгеле. Шуңа күрә авылдагы ФАПларда салкын тигәндә, тамак авыртканда эчә, тынычландыра торган дарулар һәрчак сатуда булырга тиеш.

Еракка китмибез

Россиядә яшәүчеләрнең 84,8 проценты ил эчендә сәяхәт кылуны хуп күрә. «Известия» уздырган сораштыруда катнашучыларның 6,3 проценты гына чит ил курортларына өстенлек бирүләрен белдергән. Шул ук вакытта респондентларның 5,2 проценты илне инде аркылы-буйга тулысынча йөреп чыгуларын, калганнары исә әле тагын бик күпне күрергә теләүләрен әйткән.

Эчке сәфәрләрдә иң кызыгы нәрсә, дигән сорауга болайрак җавап биргәннәр: табигый парклар һәм тыюлыклар (72,4%), истәлекле урыннар (69,3%), милли аш-су белән танышу (58,4%) һәм диңгез яры буенда ял итү (48,6%). Шул ук вакытта респондентларның 41 проценты – мәдәни-этник туризм, 31,9 проценты – актив ял, 27,8 проценты шифаханәдә сәламәтлекне ныгыту белән кызыксынуын күрсәткән.

Сораштыруда катнашучыларның 56,5 проценты Россия буйлап сәяхәтнең чит илгә сәфәр кылуга караганда кыйммәткәрәк төшүен искәрткән. 41,3 проценты ил буйлап сәяхәттә кайбер уңайлыкларның булмавын төп кимчелек сыйфатында атап үткән.

Бишлектә

Татарстан башкаласы җәмәгать транспортының сыйфаты ягыннан иң яхшы шәһәрләр бишлегенә кергән. «SIMETRA» белгечләре узган елның II кварталы азагына төзегән рейтингта Казан 70,7 балл туплаган.

Исемлекне төзегәндә транспортта бару бәясе, аның уңайлылыгы, иминлеге, инвалидлар өчен керү-чыгу мөмкинлегенең каралуы кебек күрсәткечләр исәпкә алынган.

Белгечләр фикеренчә, Казан, күпчелек өлешендә трамвай хәрәкәте туктатылуга карамастан, «миллионер» шәһәрләр арасында тариф системасын яхшырту хисабына өскә күтәрелгән.

Чаңгы бәйрәме

10 февральдә «Россиянең чаңгы юлы» ярышлары уздырылачак. Быел бу чараның 42 нче тапкыр үткәрелүе инде. Максаты – олысын-кечесен сәламәт тормыш рәвешенә җәлеп итү.

Быел ярышта катнашу өчен Дәүләт хезмәтләре порталы аша да теркәлергә мөмкин. Теркәлүне 5–9 февральдә хәл итәсе. Моның өчен табибтан махсус белешмә генә кирәк. Чарада мәдәни программалар, азык-төлек, туклану пунктлары да күздә тотылган.

Шулай итеп, бу көнне профессиональ спортчылар Казанның «Мирный» чаңгы-биатлон комплексында 2, 5 һәм 10 чакрымга узышачак. Шушы ук мәйданчыкта, Гаилә елына багышлап, 1 чакрым ераклыкка гаиләләр көч сынашачак. Казан шәһәре башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты рәисе Линар Гарипов әйтүенчә, шәһәрдә чаңгы спорты елдан-ел популярлаша бара. Бу иң элек чаңгы трассалары яктыртылуга, бик яхшы тренерлар пәйда булуга бәйле.

Коммуналь хуҗалык

Санап түләгез

Коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә киткән чыгымнарның иң югары чиген киметергә мөмкиннәр. Сүз халыкка субсидия билгеләгәндә кулланыла торган күрсәткеч турында бара.

Хәзер Татарстанда, мәсәлән, мондый ярдәмгә коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала. Дәүләт Думасы депутатлары исә әлеге чикне 10 процентка кадәр төшермәкче.

Дөрес, яңалык һәркемгә дә бер үк дәрәҗәдә кагылмый. Дәүләт Думасы комитеты җитәкчесе Ярослав Нилов хәбәр итүенчә, иң беренче чиратта пенсионерларны һәм күпбалалы гаиләләрне кайгыртырга кирәк. Нәкъ менә аларга иң югары чикне 10 процентка кадәр төшерергә тәкъдим иткәннәр дә инде.

Рәсми мәгълүматларга караганда, былтыр ил халкының ТКХ өчен киткән чыгымнары 8,7 процентка арткан. Бу – рекордлы сан. Узган ел, ут һәм су кебек, өйдәге уңайлыклар өчен 833 миллиард сумнан да күбрәк акча тотканбыз.

– Чагыштыру өчен, узган ел ил күләмендә реаль хезмәт хакы уртача 8 процентка арткан. Әле анысы да бөтен тармакта да бер үк дәрәҗәдә түгел, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Дөрес, Татарстанда хәлләр әйбәтрәк кебек. Без уртача хезмәт хакы күрсәткече буенча Идел буе федераль округында да беренче урында торабыз. Былтыр республикада реаль хезмәт хакы 13 процентка арткан. Тик ярдәмнең артыгы юк.

СУБСИДИЯ КЕМГӘ ТИЕШ?



Татарстанда халыкка ярдәм итү максатыннан, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә ташлама-субсидияләр бирү каралган. Мондый ярдәмгә коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары гомуми айлык керемнәренең 21 процентыннан артып киткән гаиләләр өмет итә ала. Субсидия рәсмиләштерү өчен яшәү урыны буенча социаль яклау бүлекчәләренә мөрәҗәгать итәргә яки дәүләт порталы аша гариза җибәрергә кирәк. Ул ярты елга билгеләнә, аннары яңадан документлар тапшырасы булачак. Акчалата ярдәмгә муниципаль яки дәүләт торагында яшәүчеләр, наем килешүе нигезендә фатир алып торучылар, торак кооперативы әгъзалары, фатир, шәхси йорт хуҗалары дәгъва кыла ала. Тагын бер шарт – торакның мәйданы. Ул билгеләнгән стандартларга туры килергә тиеш. Әлеге күрсәткечне һәр төбәк үзе билгели. Татарстанда ул бер кешегә – 40 квадрат метр, ике кешелек гаиләдә җан башына – 23 квадрат метр, өч кешелек гаиләдә – 17 квадрат метр, бер түбә астында дүрт кеше яшәсә, 14 квадрат метр тәшкил итә. Истә тотыгыз: коммуналь түләүләр буенча бурычлары булганнарга субсидия бирелми.

(Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты хәбәреннән)

Федераль таләпләр нигезендә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә киткән чыгымнарның иң югары чиге 22 процент дәрәҗәсендә билгеләнгән. Ягъни ул әнә шул чиктән узып китә алмый. Төбәкләр исә аны үзләре кимрәк итеп билгели ала. Мәсәлән, Мәскәү халкы өчен ул – 10 процент, Санкт-Петербургта яшәүчеләргә 14 процент тәшкил итә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сүзгә-сүз

Сергей МИРОНОВ,
«Справедливая Россия – За правду» фракциясе җитәкчесе:

Гаилә – кешенең таянычы. Гаиләдә төрле буын вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләр аеруча мөһим. Әбиләр һәм бабайлар аша тормыш тәҗрибәсе генә түгел, ил тарихы да тапшырыла. Алар – ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләүчеләр.

(«Парламентская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ТОРАК

2024 ЕЛГА ТӨЗЕЛЕРГӘ ТИЕШ



- **3 млн 150 мең** квадрат метр торак
- **12%** – кулланышка тапшырылган

2024 ЕЛДА ТОРАКЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ

- **930** ятим
- **28** күпбалалы гаилә (5 һәм аннан да күбрәк балалары булган)
- **84** яшь гаилә

**Республиканың Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы мәгълүматларына таянып*

Таләпләрне үтисе

Быел Россиядән Мәккәгә, узган елдагы кебек үк, 25 мең кешегә хаҗга бару мөмкинлеге бирелә. Татарстан өчен 1,8 мең урын билгеләнгән.

2024 елда фәкать яңа үрнәктәге биометрик документка – 10 елга бирелгән чит ил паспортына ия булучылар гына хаҗ кыла алачак. Хаҗиларның Согуд Гарәбстанына 9 майдан 10 июньгә кадәр керүе, ә инде 20 июньнән 1 июльгә кадәр илдән чыгуы күздә тотылган.

Быел Согуд Гарәбстаны хаҗиларны бары тик хаҗ визалары белән генә илгә кертергә ниятли. Туристлык визасы белән кереп хаҗ кылучыларга штраф салыначак.

Сүз уңаеннан, 10 мартта, кояш баеганнан соң, рамазан-шәриф аена керәбез. Бу көнне ястү намазыннан соң беренче тәравих намазы укыла. 11 март – уразаның беренче көне. Быел ураза 30 көн тотыла. Уразаның соңгы көне – 9 апрель. Ураза бәйрәме 10 апрельгә туры килә.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙДАН АКЧА КАЧА

Рәсми даирәләр никадәр генә яшерергә тырышмасын, глобаль капитализм кризисы зур һәм кызу адымнар белән атлый. Икътисадчы Нассим Талеб (кризислар турындагы мәшһүр «Каракошлар» теориясе авторы) АКШның бюджет дефициты куркыныч ноктаны узды дип саный. «Хәзер, – ди ул, – килгән зыянны могҗиза булса гына каплый ала, чөнки гигант әҗәтләр Америка икътисадын «үлем спирале»нә тартып кертә». Могҗиза булмаячак, әлбәттә. Аның урынына капитализм карчыгалары зур сугыш әзерлиләр.

Хәл бер АКШта гына катлауланса, түзеп тә булыр иде. Швейцар банкларының ышанычлылыгы тагын сорау астында дип хәбәр итә финанс белгечләре. Julius Baer банкының генераль директоры Филипп Рикенбахер отставкага китәргә җыена, чөнки финанс оешмасының хәле өметле түгел. Ул – Швейцариянең зурлыгы ягыннан икенче банкы. Үткән атнада АКШта да банк түнтәрелешләре яңадан башланды. New York Community Bancorp банкының акцияләре 36 процентка очсызлангач, алар белән сәүдәне туктаттылар. Түнтәрелеш банкның үткән кварталда көтмәгәндә зур зыян күрүе мәгълүм булгач башланды. New York Community Bancorp – Американың иң зур банклары исемлегендә. Германия зур тизлектә фәкыйрьләнә. Бу хакта илнең финанс министры Кристиан Линднер хәбәр итә. «Без бүтән көндәшлеккә сәләтле түгел. Без ярлылана барабыз, чөнки икътисадый үсеш юк», – ди ул.

Кытайда фонд базарының түбәнгә очуы дәвам итә. Чин биржаларыннан акча АКШка кача һәм Америка компанияләренә инвестицияләнә. АКШ компанияләре акцияләрендә хәзер бөтен планетадагы фонд базары капиталының яртысына якыны тупланган. АКШ фонд базары җимерелгәндә, ниләр буласын шуннан чамалый аласыз.

Кытайның фонд базары ел башыннан 1,7 триллион доллар акча югалткан. Үткән тәүлектә аз капиталлы чин компанияләренең акцияләре берничә сәгатьтә 8 проценттан артыкка очсызланды. Рәсми чин хакимиятләре вазгыятьне статистиканы бизәп йомшартмакчы булалар. Күп кенә мәгълүматлар бөтенләй игълан ителми, игълан ителгәннәре бармактан суырылган булуы белән таң калдыра. Хәзер Көнбатыш белгечләре Кытай икътисады күрсәткечләрен үзләре исәпли башлады. Финнарның BoFIT компаниясе белгечләр Күк асты илендә үткән елгы 5,2 процентлык үсеш темпының дөреслеккә туры килмәвен әйтәләр. Алар чин үсешенең кечерәк санын күрсәтә.

Бу атнада АКШ югары чиновниклар делегациясен Кытайга озатачак. Вашингтонда Кытай алып барган сәясәтне, базар икътисадына туры килми һәм халыкара базарларга яный, дип саныйлар. Компартия Вашингтон кубызына биерме, үз юлын каерырмы – атна ахырына мәгълүм булыр.

Россиядә

БАЛЫКЧЫЛАР БУРЫЧКА БАТА

Никадәр генә тотрыклы булып күренмәсен, турбулентлык Россия икътисадында да күзәтелә. Россиянең нефть эшкәртү заводлары гыйнвар аенда җитештерүне үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 4 процентка, декабрьгә мөнәсәбәтле рәвештә 1,4 процентка киметкәннәр. Кимүнең төп сәбәбе беспилотниклар һөҗүме нәтиҗәсендә кайбер заводларның зыян күрүе. «Газпромнефть», «Сургутнефтегаз», «Башнефть» кебек зур компанияләр эшкәртүне арттыруга карамастан, гомуми нәтиҗә мактанырлык түгел. Бензинның биржа бәяләре күтәрелә инде шулай булгач.

Рәсми статистика балыкчылык тармагының кредитка батуын күрсәтә. 2023 елда балыкчылар бурычы 920 миллиард сумга җиткән. Бу авыл хуҗалыгы тармагыныкына караганда 23 процентка гына ким. Масштаблар исә чагыштырырлык түгел, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләр саны ягыннан да, җитештерү күләме буенча да күпкә зуррак. 2017 елдан башлап балыкчылар кредиты авыл хуҗалыгына караганда 3,5 тапкыр тизрәк үсә икән. Темп сакланса, озакламый иген игүче һәм ит-сөт җитештерүчеләрне артта калдырачаклар. Балык бәясе дә үсеш вәгъдә итә дигән сүз бу. Тәңкәле ризык болай да акрын гына бәя үстерә инде ул. 2022 елның 27 гыйнварында Татарстанда туңдырылган бер кило балыкның уртача бәясе 218,52 сум булган. Быелның 24 гыйнварында – 261,59 сум. Аерма йомыркаһыкы кадәр үк булмаса да, сизелерлек.

Монополиягә каршы федераль хезмәт (ФАС) бәяләр үсешенә каршы җиң сызганып көрәшергә җыена. Ул бәяләр үсешен тыя торган закон проектын яңадан эшләде. Яңа проект 60 көн эчендә бәя рәсми инфляциядән 5 процентка артыграк үссә, икътисадый яктан нигезләнмәгән дип саналачак. Димәк, тыю кертеләчәк. Сер түгел, рәсми инфляция киметебрәк исәпләнә. Безнең кибетләрдә бәяләр мозаикасы исә таң калдыра торган. Бер базар белән икенче базар арасында аерма бер ярым тапкырга җиткән очраклар бар. Боларны ничек итеп тигезләп бетерерләр, аңлавы кыен. Совет чорына кайтып, бердәм бәяләр игълан итсәк кенә инде.

Финанс министрлыгы 7 февральдән, бюджет кагыйдәсенә нигезләнеп, валюта һәм алтын сатып алуга керешә. Министрлык валюта сатып ала башласа, гадәттә доллар кыйммәтләнә. Бу юлы ничек булыр, көтеп карыйк.

ЗУР ҮСӘСЕ КИЛӘ!

Яшьләр сәясәте

Зурлар белән – яшьләр телендә. Казанда ике көн дәвамында «Алдынгылар хәрәкәте» бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең слеты гөрләде. Яшьләр ел дәвамында нишләүләре һәм агымдагы елда тагын ниләр башкарырга теләүләре турында олыларга сөйләде.

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– Һәр бала әлеге хәрәкәттә күңеленә хуш килгән юнәлешне таба ала. Бу хәрәкәтнең төп мәгънәсе – балаларга, яшүсмерләргә, яшьләргә үз сәләтләрен, көчле якларын ачарга булышу, тормышта үз юлларын табуда ярдәм итү. Бу безнең илебез киләчәге өчен дә гаять мөһим.

«Урам» экстрим-паркында узган тәүге координация советында Татарстанның төрле районнарыннан җыелган 300ләп хәрәкәт активисты катнашты. Аларның башкарган эшләрен, тәкъдимнәрен Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева тыңлады.

– Сез – «Алдынгылар хәрәкәте»нең алдынгылары. Лидер ул – башкаларны да үзе артыннан ияртүче, лидер ул – төрле вазыйфаларда була алырдай кеше, иҗат итүче шәхес. Сез, иң мөһиме, илегезгә, туган төбәгегезгә, гаиләгезгә, үзегезгә файдалы булырга тиеш, – диде ул, активистларны сәламләп. – Сез команда белән эшли беләсез. Ә бит моңа да өйрәнергә, командада эшли белергә кирәк.

«Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы җитәкчесе Тимур Сөләйманов сүзләренчә, активистлар күп булсын дип, сан артыннан кумыйлар. Иң мөһиме – сыйфат. Анысын күрсәтсәң, сан да озак көттермәс. «Хәрәкәттәгеләр кызыклы, файдалы нәрсәләр белән шөгыльләнә, аларга карап, кызыгып, башкалар да кушылачак», – ди Тимур Сөләйманов.

Зурлар күп сөйләмәде, күбрәк тыңлады, дисәк, ялгышмабыз. Ә «Алдынгылар»ның сөйлисе сүзләре күп җыелган. Һәркайсы ел дәвамында төрле юнәлешләр буенча тырышкан, иҗат иткән бит!

Әнә Лаештан Нияз Шәяхмәтов «Алдынгылар хәрәкәте»нең районадагы «Алдынгылар советы»на инде 80 кеше кушылды дип таныштырды. Бергәләп башкарган эшләре дә бар: район буенча патриотик квест оештырганнар, волонтер буларак өлкәннәргә булышу белән шөгыльләнәләр (соңгы арада кар да эш өстәп торган аларга). Казан кызы Саша Ложкина «Алдынгылар хәрәкәте» белән берлектә Мәскәүдә узган «Россия» күргәзмәсендә катнашуын сөйләде һәм, мондый форумны Татарстанда да уздырып булмасмы, дип сорады. Кыз фикеренчә, күпмилләтле республиканың күрсәтерлек нәрсәләре күп, сөйләрлек тарихы бай. Чистайның кадетлар мәктәбендә укучы Глеб ватанпәрвәрлек юнәлешендә алып барган эшчәнлеге турында сөйләде.

vk.com

РУХИ БЕРДӘМЛЕК БИЛГЕСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне Татарстан Республикасы Дәүләт гербы көне белән чын күңелдән котлыйм.

Илнең аерылгысыз атрибутлары булган Герб, Флаг һәм Гимн – дәүләтнең милли-мәдәни үзенчәлекләрен үзендә туплаган, тарихи үткәннәр һәм рухи-әхлакый кыйммәтләр белән аерылгысыз бәйләнешне, территориаль һәм административ бөтенлекне чагылдыра торган символлар.

Татарстанның бүгенге дәүләт символлары өч дистә еллар элек барлыкка килде. Республика гербы 1992 елның 7 февралендә кайнар бәхәсләр аша расланды. Татарстанның дәүләт флагы төсләрендә эшләнгән гербның һәрбер элементы тирән мәгънәгә ия һәм ныклыкны, какшамас бердәмлекне, яңарыш көчен гәүдәләндерә. Милли бизәк белән каймаланган һәм өч алтын түгәрәк белән әйләндереп алынган кызыл кояш уртасына горур Канатлы Барс – Идел буе болгарларының байлык, уңыш һәм затлылык билгесе урнаштырылган. Аның күтәрелгән тәпие – югары хакимиятнең бөеклеген һәм киләчәккә омтылышны, янтыгындагы калканы– хокукый һәм икътисадый тотрыклылыкны, сигез таҗлы кашкарый чәчәге мәңгелек яшәү чишмәсен һәм озын гомерне ассызыклый.

Без республиканың төп геральдик билгесен иксез-чиксез илебезнең һәрбер почмагында гына түгел, аннан читтә дә танулары һәм ихтирам итүләре белән горурланабыз. Татарстаныбызда яшәүче төрле милләт һәм дин вәкилләре киләчәк тормышны ныклы нигездә кора. Аңа гомумгражданлык теләктәшлеге, милләтара һәм динара татулык, мәдәниятләр багланышы, традицион гаилә кыйммәтләре, Ватанны ярату салынган. Безне барыбызны да рухи бердәмлек һәм Ватанга тугрылык, республикабызны тагын да көчле һәм уңышлы итү омтылышы берләштерә.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербы көне һәрбер кешенең йөрәгендә булган мәңгелек кыйммәтләр һәм максатлар турында тагын бер кат искәртә. Хезмәт казанышларына һәм фән, мәдәният, спортта яңа биеклекләр яуларга рухландыручы әлеге изге символ киләчәк буыннар өчен дә шундый ук кадерле булыр дип ышанам.

Бу истәлекле көндә тынычлык, игелек һәм Татарстан гербы чагылдыра торган барлык изге теләкләрне кабул итегез! Сезгә бәхет, сәламәтлек һәм иминлек телим!

Химиклар урамында бәйрәм

Быел галим, күренекле химик Дмитрий Менделеевның тууына 190 ел тула. Бу уңайдан республикада, аерым алганда, аның исеменә бәйле булган «химиклар шәһәре» Менделеевскида күп чаралар узачак. Яшь галимнәр өчен иң әһәмиятлесе – химия буенча Бөтенроссия олимпиадасы.

– Менделеевск – күренекле галим исеме белән аталган бердәнбер шәһәр. Без моның белән горурланабыз. Менделеев тууына 190 ел тулу – безнең өчен икеләтә әһәмиятле дата, – диде матбугат очрашуында Менделеевск районы башлыгы Радмир Беляев. – Менделеевск бүген дә химиклар шәһәре исемен горур йөртә. Бөек химик эше турындагы тарихны һәм ул нигез салган традицияләрне саклый. Шунысы да үзенчәлекле: юбилей елы Татарстанда фәнни-технологик үсеш елына туры килде.

Күренекле галим мирасына җылы мөнәсәбәт сүздә генә түгел, гамәлдә дә күренә. Алдынгы химия заводлары һәм җитештерү предприятиеләреннән тыш, Менделеевскида бер-бер артлы белем бирү оешмалары да төзелеп килә. Әйтик, быелгы уку елында «Менделеев дәвамчылары» химия-технология лицее эшли башлады. Быел химия көллияте төзелеше башланачак. Казан илкүләм тикшеренү технология университеты филиалы үз эшен 2025 елда башлар дип көтелә. Хәзерге вакытта «Балачак академиясе» дип аталачак химик юнәлешле балалар бакчасы проекты да әзерләнә.

Сүз уңаеннан, химия буенча «Менделеев дәвамчылары» Бөтенроссия олимпиадасы 29 февральдән 3 мартка кадәр узачак. КФУ доценты Михаил Ягофаров сүзләренә караганда, сайлап алу этабында Россиянең 35тән артык төбәгеннән 700 кеше катнашкан, 60 финалист сайлап алынган.

Олимпиада ике турдан – теоретик һәм экспериментал өлештән торачак. Җиңүчеләр – 100 мең сум һәм КФУда бюджет урынында уку мөмкинлеге, призерлар 30 мең сум акча алачак. Саллы бүләкләр остазлар өчен дә каралган.

– Берничә ел элек Менделеевскида мондый олимпиада үткәрү мөмкин түгел иде. Чөнки инфраструктура юк иде. Хәзер шәһәрнең иң заманча химия лицее бар. Анда барлык кирәкле җиһазлар сатып алынган, – дип сөйләде «Аммоний» АҖ генераль директоры урынбасары Юрий Разбежкин.

Юрий Разбежкин, безнең илдә беренче урында Көнбатыш брендлары түгел, Россиянеке булырга тиеш, дигән фикердә.

– Россия империясендә хатын-кызга иң яхшы бүләк Louis Vuitton яки Chanel сумкалары түгел, ә «Менделеев чемоданы» иде. Ул чемоданнар бөтен дөньяда уңыш казанды. Бу традицияне яңадан торгызырга кирәк, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

2024 ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ
ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ

БЕР ГОМЕР АЗ

Балаларны фәнгә мәктәптән үк җәлеп итү, миллионер студентлар, яшь мөгаллимнәргә мөнәсәбәт, чит илләр белән элемтәләр. Татарстан Хөкүмәт йортында «Фән һәм университетлар» илкүләм проектына багышланган брифингта бигрәк тә менә шушы дүрт темага игътибар бирелде. Республикада игълан ителгән Фән һәм фәнни-технологик үсеш елында нинди үзгәрешләр көтә?

Татарстан Фәннәр академиясендә – яңа җитәкче. Академиянең Президенты Рифкать Миңнеханов фән өлкәсендә нинди проблемалар ачыкланган һәм Фән һәм фәнни-технологик үсеш елы аны хәл итәргә ничек ярдәм итә ала – шул хакта сөйләде:

– Академиядә проблемалар юк. Россия күләмендә нәтиҗәләр зур. Бәлки, технологик яктан эш азрак алып барылгандыр. Аның структурасы да юк иде, хәзер бераз үзгәрешләр кертәбез. Без төрле идарәләр, лабораторияләр булдырып, үзебез нәрсәдер эшли башлый алмыйбыз, – диде Рифкать Миңнеханов. – Иң беренче урында – барысын да берләштерү һәм нәтиҗәгә ирешү. Министрлыклар, төрле оешмалар безнең сорауларга ныклап игътибар итсен иде. Бюджет акчасы гына түгел, инвестицияләр венчур фонды да бар. Бер елда гына фәнне үзгәртеп булмый. Барлык эшне берләштереп, системага салырга кирәк.

Инженерлар җитми

Галимнәр авыл мәктәпләренә барамы? Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллиннан журналистлар шул хакта кызыксынды. Аның әйтүенчә, яшьләрне фәнгә тарту – катлаулы хезмәт. Әгәр галимнәр мәктәпләргә барып, балалар белән очрашулар үткәрмәсә, укытучылар моны үзләре генә башкарып чыга алмый. Шул ук вакытта министр галимнәрнең мәктәпләргә элеккеге кебек актив йөрмәвен дә яшермәде. «Шуңа карамастан, без бу эшне яхшыртырга тиеш», – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Илсур Һадиуллин ассызыклаганча, хәзерге вакытта илдә инженерлар әзерләү юнәлеше буенча проблема зур. Әлеге кадрлар җитми. Шул уңайдан республикада мәсьәлә көчәйтелгән. Быелгы уку елында инженер сыйныфлары күбрәк ачылган.

– Гуманитар юнәлештә безнең хәлебез начар түгел, ул – үсештә. Ә менә физика, математика, химия буенча яшьләрне җәлеп итү зур бурычларның берсе булып тора. Безнең мәктәпләрдә 161 мәктәп урманчылыгы эшли. 132 мәктәптә экологик сыйныфлар ачылды, – диде Илсур Һадиуллин.

Миллионер студентлар

Республика – «Студентлар стартабы» конкурсында җиңүчеләр саны буенча илдә беренче. Бездә 442 миллионер студент бар. Алар стартапларны тормышка ашыру буенча 1әр миллион сум акча откан. Фәнни проектлар тормышта да кулланылачак. Сүз уңаеннан, бу – яшьләргә технологик эшкуарлыкта үзләрен сынап карау өчен менә дигән мөмкинлек. Ә алар беренче миллиардларын кайчан эшләр икән? Журналистларның әлеге соравына Татарстан Рәисе ярдәмчесе Альберт Гыйльметдинов җавап бирде.

– Әлеге проектка ким дигәндә ике генә ел әле. Моның өчен нәтиҗәне ун ел көтәргә кирәк. Бу инде – компания-единорог (базардагы бәясе 1 миллиард доллардан артыграк күләмдә бәяләнгән компания-стартап) дигән сүз. Проектларның күбесе озын гомерле булмаска мөмкин, бу – нормаль күренеш. Монысына да әзер булырга кирәк, – диде ул.

Мөнәсәбәт

Чит ил галимнәре белән элемтәләр яхшы. Белгечләр шулай дип ышандырырга тырышты. Алдагы елларда Көнбатыш белән шактый күп эш башкарылган. Хәзер геосәясәткә бәйле вазгыять үзгәргән. Игътибар күбрәк Көнчыгышка күчкән. Кытай, Һиндстан, Иран, Гарәп илләре, Казахстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан белән хезмәттәшлек көчәйгән. Әмма шул ук вакытта Көнбатыш галимнәре белән элемтәләр өзелмәгән. Вузларда чит ил студентлары өчен стажировка мәйданчыклары булдырылган. Безнекеләр дә аларга тәҗрибә уртаклашырга бара.

– Берара тынлык булып алды да шуннан соң хәлләр җанланып китте. Галимнәрне халыкара фәнни чараларга чакыралар, Көнбатыш журналларында хезмәтләр бастыру буенча тәкъдимнәр күп килә, – диде Альберт Гыйльметдинов.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Татарстан соңгы өч елда вузларга федераль акча бүлеп бирү буенча өченче урында тора. 2021–2024 елларда югары мәктәпне үстерү программасы кысасында өстәмә рәвештә 4,6 миллиард сум акча җәлеп ителгән.

Язгы утырышлар башлана

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының илле беренче утырышы (язгы сессиядә – беренче) 15 февральдә үткәреләчәк. Парламент Президиумында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 31 мәсьәләне, шул исәптән 11 республика, 10 федераль закон проектын һәм Карелиянең Законнар чыгару Җыены закон тәкъдимен карауны күздә тота.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карауга керешкәнче, гадәттәгечә, соңгы вакытларда республикада депутатлар катнашында узган кайбер мөһим вакыйгаларны билгеләп үтте. 5 февральдән республиканың барлык мәктәпләрендә, Россия һәм Татарстанның сайлау системасы нигезләрен аңлатуга багышлап, «Киләчәкне сайлыйбыз!» дигән парламент дәресләре башланып киткән. Фәрит Мөхәммәтшин депутатларны бу чарада актив катнашырга чакырды.

Алдагы утырышка килгәндә, Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, көн тәртибенә кертелгән барлык 11 республика законы проекты беренче укылышка әзерләнгән. Болар – дәүләт граждан хезмәте турында республика законына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына, җирле үзидарә турында, Татарстан Бюджеты кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан һәм башка шундый закон проектлары.

Депутатлар утырышта шулай ук эчке эшләр министрының узган елда полиция эшчәнлеге турында, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең 2023 елдагы эшчәнлеге турында чыгышлар һәм 2021–2030 елларда Казан университетын үстерү программасын тормышка ашыру турында хисап тыңлаячак. Сүз уңаеннан, университетның үсеш программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләренең Дәүләт Советында һәр ел саен каралуын искәртеп үтәргә кирәк.

Язгы сессия – алтынчы чакырылыш парламенты эшендәге соңгысы. Бу чорда гадәттә Дәүләт Советы комитетлары законнар иҗат итү буенча башкарылган эшләре турында хисапларын төзүне төгәлли. Якындагы утырышта Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эше турында хисап каралачак.

Бу сессиянең төп мәсьәләләреннән берсе – Хөкүмәт хисабы. Республика башкарма хакимияте органнарының узган елдагы эшенә йомгак ясалган төп документ апрель аенда Дәүләт Советы утырышында каралачак.

Дәүләт Советында Хөкүмәтнең 2023 елдагы эшчәнлеге буенча хисабын карап тикшерү эше башланган да инде. Аерым алганда, Президиум утырышында башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында комитетлар һәм депутатлар берләшмәләреннән алынган сораулар исемлеге расланып, республика Рәисенә җибәрелде.

Президиум утырышында шулай ук Дәүләт Советының 2024 елга эшен оештыру буенча чараларның үрнәк планы расланды. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов билгеләп үткәнчә, план Дәүләт Советы эшчәнлеге өлкәләрен тулысынча чагылдыра. «Быел контроль мәсьәләләрен карап тикшерү аерым игътибар үзәгенә алыначак. Хәзер комитетларның бер генә утырышы да алардан башка гына узмый, контроль мәсьәләләре Дәүләт Советы Президиумының һәр утырышының көн тәртибенә кертелә», – дип басым ясап әйтте ул.

Утырышта «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» республика газеталарының баш мөхәррирләре Гөлнара Сабирова белән Алексей Угаровның узган елгы йомгаклар буенча редакцияләрнең дәүләт заданиеләрен үтәүләре турындагы чыгышлары да тыңланды. «Бер генә хакимият тә массакүләм мәгълүмат чараларыннан башка гына һәм халык белән турыдан-туры элемтәдә тормыйча гына яши алмый, – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин, фикер алышуга йомгак ясап. – Ә рәсми басмаларга – «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына мәгълүматның тиз һәм дөрес бирелүе аеруча мөһим». Парламент башлыгы газеталарның баш мөхәррирләре игътибарын аңлату эшенең, республика шәһәрләре һәм районнарында газета укучылар белән даими очрашуларның мөһимлегенә юнәлтте.

Президиум утырышында башка мәсьәләләр дә каралды.

Белдерү

Кадастровым инженером Биктимировым Ильшатом Ринатовичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-я Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600482408, электронная почта biktimirov_i@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-10-80), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:060404:1, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, ул. Бухарская, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Афлятунов Ренат Рафаэлевич, почтовый адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Б.Армавирская, д. 170.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10.00 ч. до 18.00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1, 11 марта 2024 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:50:060404:4; 16:50:060404:12; 16:50:000000:645; 16:50:060404 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышын 2024 елның 15 февралендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 феврале
№ 2319-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле беренче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. 2023 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры хисабы.
3. 2023 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап.
5. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 526-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 527-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 531-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 525-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2^1 статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 520-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 521-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 529-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 522-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 530-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 528-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 524-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының 2019 елның сентябреннән 2024 елның февраленә кадәрге эш чоры өчен хисабы.
17. Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
18. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.
19. Александр Васильевич Тыгинның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комитетлары составларындагы үзгәрешләр турында.
21. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 519947-8 номерлы федераль закон проекты турында (закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты закон чыгару органына Дәүләт Думасында закон чыгару инициативасы турында тәкъдим кертү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).
22. «Россиянең Хәрби дан көннәре һәм истәлекле даталары турында» Федераль законның 1^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 522576-8 номерлы федераль закон проекты турында («1 июль – Хәрби хәрәкәтләр ветераннары көне» Россиянең истәлекле датасын билгеләү хакында).
23. «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан саклау турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 519375-8 номерлы федераль закон проекты турында (мәгълүмат продукциясенә экспертиза ясауга гомуми таләпләрне төгәлләштерү өлешендә).
24. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 519732-8 номерлы федераль закон проекты турында (хокукка каршы кылынган бер үк гамәлгә карата төрле административ-хокукый нормалар нигезендә кузгатылган административ хокук бозулар турындагы эшләрне башкару тәртибе хакында).
25. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 498488-8 номерлы федераль закон проекты турында («медицина ярдәме» төшенчәсен төгәлләштерү өлешендә).
26. «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке тарту яисә никотинлы продукция куллану зыяннарыннан саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 521876-8 номерлы федераль закон проекты турында (җылытыла торган тәмәкесез катнашмаларны җайга салу өлешендә).
27. «Концессия килешүләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 509734-8 номерлы федераль закон проекты турында (концессия килешүләре объекты мәгълүмат технологияләре булган концессия килешүләре механизмын камилләштерү өлешендә).
28. «Россия Федерациясендә стандартлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 517404-8 номерлы федераль закон проекты турында (продукция белән эш иткәндә оешмалар стандартларын, шул исәптән техник шартларны, куллану өлешендә).
29. «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән хәвефсез эш итү турында» Федераль законның 15^2 статьясына һәм «Россия Федерациясендә умартачылык турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 500293-8 номерлы федераль закон проекты турында (федераль законның үз көченә керү срогын күчерү өлешендә).
30. «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законның 62^2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 501344-8 номерлы федераль закон проекты турында (яшел урман паркы поясын булдыру өлешендә).
31. «Россия Федерациясе Җир кодексының 11^{10} статьясына һәм «Кадастр эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең инициативасы турында.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 феврале
№ 2320-VI ДС

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача күләмен раслау турында

ХӘБӘРНАМӘ

Россия Федерациясе Җир кодексының 66 статьясындагы 2 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.12.2023 ел, № 3963-р боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача күләме расланды.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.12.2023 ел, № 3963-р боерыгы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2024 елның 02 февралендә расланды (№ 12493).

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача күләме белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында (https://mzio.tatarstan.ru/) танышырга мөмкин.

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

БОЕРЫК

29.12.2023 ел Казан ш. № 3963-р

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 66 статьясындагы 2 пункты, «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 ел, № 407 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» турында нигезләмәнең 3.3.81 пункты нигезендә:

1. Бу боерыкка кушымта нигезендә, 2022 елның 1 гыйнварына билгеләнгән Татарстан Республикасы муниципаль районнарында җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең уртача күләмен расларга.
2. Бу боерыкны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернат» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (https//:mzio.tatarstan.ru/) урнаштырырга, Татарстан Республикасы рәсми басмаларында – «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.
3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Министр Ф.Ә. Әһлиуллин

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционер җәмгыяте» акционер җәмгыяте генераль директоры **Галимов** Рафаэль Равил улы, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә мөһим өлеш кертүе өчен шагыйрь, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Ибраһимов** Илфак Мирза улы, күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге, татар халкының телен һәм мәдәниятен үстерүгә һәм саклауга мөһим өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсе башлыгы **Миңнуллин** Ким Мөгаллим улы, спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (Казан шәһәре) тренеры-табибы **Сәгыйтов** Илшат Тәүфикъ улы, республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе өчен һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Буа элеваторы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Хакимов** Газинур Хәбибулла улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«Арча муниципаль районы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Әһлиев** Илдус Куттус улына, «Каздорсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Попов** Николай Ильичка **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Әгерҗе муниципаль районындагы «Наз» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют» дәүләт казна учреждениесе директоры **Нигъмәтуллина** Гөлчәчәк Рамазан кызына, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Платонова** Мария Андреевнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Энерготранс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең хезмәтне саклау буенча белгече **Алиев** Илгиз Хәбибулла улына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының гомуми бүлеге автомобиль йөртүчесе **Габидуллин** Рәйхәт Яһүд улына, «Ремдизель» акционер җәмгыяте эчке логистика хезмәтенең транспорт цехы автомобиль транспорты участогының автомобиль йөртүчесе **Сәгыйдуллин** Азат Әнәс улына, «Ремдизель» акционер җәмгыяте эчке логистика хезмәтенең транспорт цехы автомобиль транспорты участогының автомобиль йөртүчесе **Харисов** Илфат Фатих улына, «Ремдизель» акционер җәмгыяте эчке логистика хезмәтенең транспорт цехы автомобиль транспорты участогының автомобиль йөртүчесе **Циренов** Сергей Николаевичка, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Үзәк инфраструктура дирекциясе структур бүлекчәсе – Куйбышев инфраструктура дирекциясе структур бүлекчәсе – Круглое Поле эксплуатация вагон депосының вагоннарны өлкән тикшерүче-төзекләндерүчесе **Галиев** Айрат Мәзхәт улына, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Үзәк элемтә станциясенең Түбән Новгород элемтә дирекциясе структур бүлекчәсе – Ижевск төбәк элемтә үзәге инженеры (сменалап эшләүче хезмәткәре) **Назипова** Фәйрүзә Рифкать кызына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча саклана торган табигать территорияләре өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге район (районара) бүлеге башлыгы **Жиганов** Евгений Павловичка, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе гомуми бүлеге башлыгы урынбасары **Пашонина** Ольга Сергеевнага, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча инспекциясе күчмә тикшерүләр бүлеге баш дәүләт салым инспекторы **Кузьмина** Клавдия Агафоновнага, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге өлкән белгече **Сафиуллина** Гөлнара Рәис кызына, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының дәүләт хезмәтен үстерү бүлеге баш киңәшчесе **Соколов** Игорь Николаевичка, Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банкның финансларны мониторинглау һәм валюта контроле бүлеге кредитлар бирү белән шөгыльләнмәүче финанс оешмаларының финансларын мониторинглау һәм валюта контроле секторы мөдире **Мартиросова** Эллина Георгиевнага, Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банк идарәчесе урынбасары **Хәбибуллина** Диларә Таһир кызына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы урынбасары **Умарова** Оксана Андреевнага, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы **Козлов** Вячеслав Михайловичка, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге мөдире **Шрша** Равия Бәдретдин кызына, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе Операция бүлеге башлыгы **Нуруллина** Лилия Фәез кызына, «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ регионы автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенең юл корылмалары бүлеге башлыгы **Айнетдинов** Рамил Рөстәм улына, «Татнефтедор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте филиалы Азнакай автомобиль юллары идарәсенең участок башлыгы **Әхмәдишин** Рамил Марс улына, «Күпер» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Галимов** Фиргать Әсгать улына, «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсенең Әлмәт автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы **Әхмәтов** Илдар Фәрит улына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе методисты **Бильданова** Әлфия Сәлимгәрәй кызына, «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы өлкән инструкторы-методисты **Гаптуллин** Фәрит Шәрифулла улына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башлыгы **Заһидуллин** Ирек Гали улына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы **Нәҗипов** Габдерәшит Газиз улына, «Биектау сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Шәйхетдинов** Рафис Тәбрис улына, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директорының гражданнар өчен продукция эшләү буенча урынбасары **Әхмәтов** Марат Мәхмүт улына, «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте 6 номерлы цехының җыю эшләрен тәмамлаучы эшчесе **Гаранин** Юрий Александровичка, «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте 20 номерлы цехының хезмәтне оештыру һәм хезмәт хакы бюросы башлыгы **Котельникова** Луиза Ринат кызына, «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте 25 номерлы цехының металл суднолар корпуслары җыючысы **Параков** Александр Сергеевичка, «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте 20 номерлы цехының суднолар буяучысы **Шалтынова** Марина Геннадьевнага, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Документлар белән тәэмин итү идарәсенең Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив-хокукый документлары текстларын тәрҗемә итү һәм тәңгәлләштерү бүлеге баш киңәшчесе **Исмәгыйлова** Гөлназ Хәмзә кызына, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге социаль түләүләр билгеләү идарәсе башлыгы **Хәбибуллин** Ирек Рафаил улына, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары **Шашуров** Сергей Евгеньевичка, «Төзелеш ТК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Никитин** Владислав Петровичка, «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзелеш буенча директоры **Насыйров** Руслан Рафаил улына, «СтройМонтаж-Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шайбулатов** Николай Леонидовичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Мач әйткән!



Оноре де БАЛЬЗАК, язучы:
– Үзенең көчсезлеген таныган кеше көчле була.

Киявгә чыгу – түгел сөйләнү

– Әти, егетем минем кулны сорарга килгәч, «Аллага шөкер! Ниһаять!» дип кычкырасы түгел, яме.

***

Әбидә кунакта булдым. Йокларга ятып, 40 минут узуга, әби кычкыра:
– Йоклыйсыңмы?
– Әйе.
– Түбән очтан Марат өйләнмәгән бит, менә дигән егет!

***

– Бәхет тынычлыкны ярата, диләр. Ничек инде? Юкка гына чибәр егет эзләдеммени мин?

***

– Без өйләнешкәч, бөтен шатлык һәм борчуларыбыз уртак булачак.
– Минем бернинди борчуларым да юк.
– Өйләнешкәч, – дим бит.

***

– Мин башка кызлар кебек түгел. Миңа чәчәк кирәкми. Миңа коттедж кирәк.

***

– Ой! Кем син?
– Мин – синең акылың. Мәхәббәтеңне очраттың бит, саубуллашырга кердем.

***

Элек әниең сине 18 яшьтә бала тапмаса ярар иде дип борчыла иде, хәзер 30 яшькә кадәр бала тапса ярар иде дип борчыла.

***

– Синең мине берәр кайчан югалтырмын дип курыкканың бармы?
– Хәтерлисеңме, автобуска чаба идек, ә билетлар синең кесәдә иде.

***

– Синең, гомумән, егетләр белән берәр җитди мөнәсәбәт булганы бармы?
– Бар. Берсендә хәтта судка кадәр барып җиттек.

«Иж-Планета» мотоциклы сатып алам. Космик бәяләр тәкъдим итмәгез.

ӘГӘР ЛЕНИН ИСӘН БУЛСА...

Мин Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекторий бүлегендә эшләдем. Бу бүлекнең максаты чын профессиональ музыканы пропагандалау, аерым авторларның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрү һәм, әлбәттә, илебез күләмендә билгеләп үтелгән бәйрәмнәргә махсус программалар әзерләү иде.

Апрель аенда совет халкы өчен бөек Ленинның туган көне һәм шуңа да безнең бүлек әзерләгән барлык программалар да Ильич исеменә бәйле булырга тиеш иде. Язның шушы матур көннәрендә без Гали Ильясов белән «Любимые песни Ильича» дигән әдәби-музыкаль темада бер төркемдә туры килдек. Гали башка җырчылардан аермалы буларак, темага карап тормый, Ильич яраткан «Есть на Волге утёс», «Дубинушка»лардан соң үзе иҗат иткән «Оныттың бугай»ны да сылый. Бөек юлбашчының яраткан җырларыннан оеп утырган тамашачы гөрләтеп кул чаба, Галигә рәхмәтләр әйтеп, башка җырларын да җырлавын үтенәләр. Шулай итеп, «Любимые песни Ильича» әдәби-музыкаль композициясе әкренләп Гали Ильясовның иҗат кичәсенә әйләнә.

Әлбәттә, бу хәлне кичәне рус телендә алып барган нәфис сүз осталары җитәкчелеккә җиткерәләр. Җыелышларның берсендә Гали әфәндегә шундый сорау бирәләр:

– Гали Ганиевич, әйтегез әле, ни өчен сез Ленинга багышланган җитди кичәнең эчтәлеген юкка чыгарып, үзегез иҗат иткән «Бугай»ны башкарасыз?

– Ә сез беләсезме, әгәр Ильич исән булса, ул бу җырны, һичшиксез, яратыр иде, – дип җавап кайтара Гали Ильясов.

Нәҗип БӘДРЕТДИНОВ

СӘНӘГЕҢНЕҢ ҖӘБЕН КИС

Бәләкәй чактан ук эшкә өйрәнеп үстек без. Өй, каралты-кура, мал-туар, кош-корт – бетәмени мәшәкать?! Үсә төшкәч, өлкәннәр арасында да эш кыймылдата башладык. Бигрәк тә колхоздагысы – күмәклек, ил-Ватан өчен дигән хезмәт дәртләндерде безне. Ул вакытта нинди гамәл кылсаң да, монысы зурга, ә менә монысы кечкенәгә бүленмәде. «Эшләгәнең ил өчен булса, өйрәнгәнең – үзең өчен!» дигән гыйбарә бар иде. Менә монысы – хәзер сөйләргә теләгәне мәзәгрәк истәлек булса да, язып үтим әле.

Җәй. Печән чабабыз, киптерәбез, өеп куябыз – бер сүз белән әйткәндә, мал-туарга кышка курмы әзерлибез. Кырда иген игелгәч, комбайн саламын күчләп калдыра, аны җыябыз, өябез. Дустым Җәүдәтнең әтисе Даһиз абый – кибән өстендә. Без биреп торган салам-печәнне таптый-җайлый тора. Инде байтак өскә чөйгән печәнебез кабат коелып төшә. Даһиз абый тотып калырга өлгерми башлый. Бу очракта җәпле, озын саплы агач сәнәккә күчәбез. Алай да җиткерә алмый башлагач, абзыебыз иелеп ала башлый.

Кайвакытта, күрәсең, сәнәкнең очы Даһиз абыйга да төртелә – улына әйтеп куйгалый:

– Ах, анаңның... «тегеләй-болай» – сәнәгеңнең җәбен кис! – дип.

Шул әйтем безнең яктагы халыкта бик ныгып калды, искә еш төшергәлиләр.

Алмаз ХӘМЗИН

Әз-мәз мәзәк

– Без кунакка килмәсәк, алар шатланачак кына.
– Әйе, барырга кирәк.

***

– Матурым, бу кичәге ашмы әллә?
– Кичәге генә түгел, әле иртәгәге дә.

***

– Балалардагы нәрсәне яратасың?
– Аларның минеке булмауларын.

***

– Доктор, корсакны ничек бетерергә?
– Аркагыз белән борылыгыз.

***

– Матурым, ә син миңа яратып өйләндеңме?
– Әлбәттә, яратып. Башкача бу адымны берничек тә аңлата алмыйм.

***

Урамда аккумулятор күтәргән мужикны күрсәгез, димәк, бүген салкын.

***

– Менә элек ничек иде?
– Ничек?
– Әйтмә дә!
– Ә хәзер ничек?
– Шул шул!



Һөнәрең матур, сине монда кем куйган?

– Доктор, бүтән сездә дәвалана алмыйм.
– Ни булды?
– Акчам бетте.
– Савыгуыгыз белән котлыйм!

♥♥♥

Ни өчен сүзләрне бозып сөйләшү модага керде? «Төшке аш» урынына – «ланч», «яллар» урынына – «уикэнд», «эшсез» урынына – «блогер»?

♥♥♥

Фрилансер эшен вахтёр эше белән берләштерсәң, офис өчен түлисе булмаячак. Әле үзләре сиңа түләячәкләр.

♥♥♥

– Доктор, минем башымда нининдидер көйләр яңгырый.
– Шуннан?
– Мин андый репертуар яратмыйм.

♥♥♥

Ир-хатын мөнәсәбәтләрендәге 1 ай тәҗрибә психологтагы ярты сәгать консультациягә тиң.

♥♥♥

– Официант! Мин инде ике сәгать койка-холодец көтеп утырам!
– Хәзер пешеп чыга.

♥♥♥

Айти-компаниягә җыештыручы апа кирәк. Карьера буенча үсеш гарантияләнә. Конференцияләрне тыңлау – бушка.



ИДЕАЛЬ ХЕЗМӘТКӘР

1. Берничә югары белемле.
2. 100 еллык эш стажы бар.
3. Яшь һәм актив.
4. Өч тиенгә эшләргә әзер.
5. Премияләрне кирәксенми.
6. Стресска түзем.
7. Беркайчан авырмый.
8. Бала тапмый.
9. Йокламый.
10. Эштән башка бер кызыксынуы да юк.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Бер фото тарихы

Алма-Атаның «Медео» шугалагын күпләр беләдер. Элекке заманда Советлар Союзының төрле почмакларыннан бик күп туристлар булган анда. 1980 нче еллар ахыры. Җирле газетаның Олег Иванов исемле фотографы шугалакка килә. Шунда Алена Островская исемле таныш журналист кызны очрата. «Медео» шугалагы таулар арасында бик матур җирдә урнашкан. Монда һава торышы да үзенчәлекле. Алена, кояшта кызынам дип, купальниктан гына тимераякта шуа. Таныш фотографы белән күрешеп, бераз сөйләшкәч, шуууын дәвам итә. Якында гына авыл хезмәтчәннәре төркеме. Элек алдынгыларны шулай экскурсия белән бүләклиләр иде. Араларында күкрәгенә медальләр таккан бер бабай да бар. Олег Иванов аны фотога төшерергә рөхсәт сорый. Бабай каршы килми, шугалакка ук чыгып баса. Гәрчә тимераяксыз кешеләрне боздан куа торган булганнар. Гөнаһ шомлыгына, шул мизгелдә якында гына купальниклы Алена узып барган. Ул да тиз генә объектив каршына килеп баса. Бабай исә югалып кала торганнардан түгел, чибәркәйне кулыннан ук тотып ала. Менә шулай барлыкка килгән фото бу. Шунысын да әйтергә кирәк: ул чакта бүгенге сыман 5–6 кадр ясамаганнар. Олег төймәгә бер генә тапкыр баскан, чөнки фототасманы әрәм итәргә ярамый, һәр кадр өчен редакциядә хисап тотасы! Цензура аркасында бу фото күп еллар халыкка чыгарылмаган. Соңрак исә, дөнья күргәч, төрле фотобәйгеләрдә җиңүләр яулаган. Алена хәзер Америкада яши ди. Башта аңа бу фото турында әйтергә курыкканнар. Кем белә бит, сөйгән яры, бәлки, бабайга көнләп куяр. Зерә курыкканнар. Алена бу фотоны күргәч, чын күңелдән көлгән генә. Һәм яшьлек елларындагы бабайны җылы итеп искә алган.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 214

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+